ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 511 от «25» 12 2025 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023 елның
2 октябрендәге № 388 карарына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасы турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 11 ноябрендәге 480 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 16 декабрендәге 1091 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 2 октябрендәге «Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы турында» № 388 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы турында нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) (02.12.2024 ел, № 425; 11.12.2024 ел, 448; 14.01.2025 ел, № 10; 14.03.2025 ел, № 99; 16.12.2025 ел, № 491 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 17 пунктына 17 түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә: «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның финанс һәм матди ресурслары резервлары, әгәр бу күрсәтелгән резервларны булдыру һәм алардан файдалану тәртибендә каралган булса, югары әзерлек режимын керткәндә файдаланылырга мөмкин.»;

1.2. Нигезләмәнең 19 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. ТСЧСта мәгълүмат белән тәэмин итү «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә системасы» дәүләт мәгълүмат системасын, шулай ук мәгълүмат бирүнең башка ысулларын кулланып гамәлгә ашырыла.»;

1.3. Нигезләмәнең 21 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян

0000015102

итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе, җирле үзидарә органнары һәм территорияләрендә Гадәттән тыш хәлләр килеп чыгарга яисә килеп чыгарга мөмкин булган йә вәкаләтләренә гадәттән тыш хәлләрне бетерү кертелгән оешмалар җитәкчеләре карарлары белән тиешле идарә органнары һәм ТСЧС көчләре өчен түбәндәге эшчәнлек режимнарының берсе кертелергә мөмкин:»;

1.4.Нигезләмәнең 22 пунктында:

- беренче абзацта «җитәкчеләрне» сүзен төшереп калдырырга, «җирле үзидарә органнарының һәм» сүзләреннән соң «җитәкчеләрен» сүзен өстәргә.;

- җиденче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре» сүзләренә алмаштырырга»;

- җиденче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. Нигезләмәнең 23 пунктында «җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре билгеләгәннәрне гамәлдән чыгара» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре кертелгәннәрне гамәлдән чыгара» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.М.Ефимов